**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ**
**НИЖНЕКАРМАЛКИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423102, СЕЛО НИЖНЯЯ
КАРМАЛКА, УЛ.ЛЕНИНА, Д.44

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ТҮБӘН КАРМАЛКА АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

423102, ТҮБӘН КАРМАЛКА АВЫЛЫ,
ЛЕНИН УРАМЫ,44 ЙОРТ

Тел.: (84396)2-39-47 ФАКС: (84396) 2-39-47
Email: Nkar.Cmn2@tatar.ru

№ 121 15.12.2023 ел

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Түбән Кармалка авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге Советының 2013 елның 14 мартындагы № 48 «Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне, чикләүләрне һәм тыюларны һәм коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен җәзаларны куллану тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

2023 елның 13 июнендәге № 258-ФЗ, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге № 286-ФЗ Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге Уставы белән Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге Советының 2013 елның 14 мартындагы № 48 «Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне, чикләүләрне һәм тыюларны һәм коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен җәзаларны куллану тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» карарына (Советның 2018 елның 21 декабрендәге № 106, 2021 елның 30 сентябрендәге № 38, 2021 елның 22 декабрендәге №49, 2023 елның 16 мартындагы № 84 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.4 пунктчасының 2 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: «үз карамагындагы муниципаль хезмәткәрдә шәхси кызыксыну барлыкка килүе турында белгән яллаучы вәкиле булган муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләр конфликтына китерә яки китерергә мөмкин булган мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча чаралар күрмәве, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш;».

1.2. 2.5 пунктның 1 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә: «1) федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау

буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәтенең кадрлар бүлеге үткәргән тикшерү нәтиҗәләре турында доклад;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында бастырып чыгарырга (parvo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Түбән Кармалка авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе А.Ф. Митякин